**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Мичурин торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Мичурин торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Мичурин торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Мичурин авыл җирлегенең Мичурин торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәү урыны Мичурин авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, шулай ук I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, МХОда катнашучылардан тыш, 500 (Биш йөз) сум күләмендә күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мичурин ис.п. Совет урамы буенча авыл эчендәге юлны чокырларга ремонтлау, Мичурин ис поселокта юлларны кардан чистарту).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мичурин исемендәге поселок ур., Совет ур., 26 йорт – административ бина, Совет ур., 28 йорт – мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк ур., 9 йорт – мәдәният йорты бинасы, Үзәк ур., 15 йорт – мәктәп бинасы, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Мичурин авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Иванова